ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР №13

Акбаш ав. 2022 елның 8 июле

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл
җирлеге Советы
карарын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2021 елның 27 октябрендәге «Тикшерү кәгазьләренең формаларын эшләү, эчтәлегенә, җәмәгать фикер алышуына, раслауга, куллануга, актуальләштерүгә, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларына карата таләпләрне раслау турында»гы 1844 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль мәсьәләләр исемлеге) формасын раслау турында»гы 6 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Синагатуллина